# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 26 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Янгын куркынычсызлыгы турында" 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2012, 8 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяда:
а) дүртенче өлештә ", шул исәптән янгыннан ирекле саклануны" сүзләрен төшереп калдырырга;
б) бишенче өлештә "Янгыннан ведомство, хосусый һәм ирекле саклану" сүзләрен "Янгыннан ведомство һәм хосусый саклану" сүзләренә алмаштырырга;
в) түбәндәге эчтәлекле алтынчы өлеш өстәргә:
"Янгыннан ирекле саклану эшчәнлеген финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү, шулай ук ирекле янгын сүндерүчеләргә социаль гарантияләрне һәм компенсацияләрне финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.";

2) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Янгыннан ирекле саклану**

Янгыннан ирекле саклану Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә оештырыла һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2012 елның 17 мае
№ 20-ТРЗ